РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**Большекляринского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советская, 9,с. Большие Кляри, 422837
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 93064636, ОГРН 1061672003403
ИНН/КПП 1622004605/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Кариле**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Совет урамы, 9,Олы Кариле авылы, 422837,
тел. (84377)32-2-42, факс: (84377) 32-2-42
ОКПО 93064636, ОГРН 1061672003403
ИНН/КПП 1622004605/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**2018 ел, 4 сентябрь** **№5**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 15 июнендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 4 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 8 июнендәге 4нче номерлы карары редакциясендә)**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 15 июнендәге 4 санлы карары белән (2018 елның 8 июнендәге 4нче номерлы карары редакциясендә) расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”;

1.2. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакөиядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16; шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.Г. Гарифуллин**